# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
# ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

## КАРАР

«24» 09 2025 ел Яр Чаллы №3188

«2021 елга ведомство карамагындагы оешмаларда хезмәт законнарының һәм башка норматив хокукый актларның үтәлешенә тикшерүләр үткәрү нигезләмәсен һәм еллык планын раслау турында» карарга үзгәрешләр кертү хакында

«Татарстан Республикасында хезмәт законнарының һәм хезмәт хокукы нормаларын үз эченә алган башка норматив хокукый актларның үтәлешенә ведомство контроле турында» 2009 елның 27 ноябрендәге 100-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының (алга таба – 100-ТРЗ номерлы Закон) 4 статьясы 3 пункты нигезендә

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының «2021 елга ведомство карамагындагы оешмаларда хезмәт законнарының һәм башка норматив хокукый актларның үтәлешенә тикшерүләр үткәрү нигезләмәсен һәм еллык планын раслау турында» 2021 елның 23 мартындагы 866 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карар исемендә «...2024 елга» сүзләрен «...2025 елга» сүзләренә алыштырырга.

1.2. 2025 елга Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының ведомство буйсынуындагы оешмаларда хезмәт законнарының һәм хезмәт хокукы нормаларын үз эченә алган башка норматив хокукый актларның үтәлешенә тикшерүләр үткәрү планын 2 кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

1.3. Комиссия составыннан чыгарырга:

- А.Р. Хәбибуллинны;
- М.А. Потеевны;
- Г.Р. Батыршинаны
- Н.К. Бузинаны;
- К.Р. Нәҗмиевны.

1.4. Комиссия составына кертергә:

- Маняпов Линар Нурислам улын – Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе вазифаларын башкаручы;
- Лымарь Розалия Рафаил кызы – «Тукай районы үзәк хастаханәсе» ДАССУ баш табибы;

- Хәкимова Эльмира Вәзәҗетдин кызын – Татарстан Республикасы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге дәүләт казна учреждениесенең Яр Чаллы шәһәре һәм Тукай районы буенча департаментының Тукай районы буенча гражданнарны кабул итү бүлеге башлыгы;

- Вәлиева Гөлназ Зөфәр кызын – Тукай муниципаль районы Советының юридик бүлеге башлыгы.

2. Әлеге карарны муниципаль районның рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе
Вазифаларын башкаручы Л.Н. Маняпов

Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2025 елның 24 сентябрендәге 3188 номерлы карарына 3 кушымта

**Ведомство контроле буенча чаралар үткәрүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеге**

**Комиссия рәисе:**

Маняпов Л. Н. – Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе вазифаларын башкаручы;

**Комиссия әгъзалары:**

1. Вәлиева Г.З. – Тукай муниципаль районы Советының юридик бүлеге башлыгы;
2. Низамиева Э.Р. – «Тукай муниципаль районы мәгариф идарәсе» МКУ башлыгы;
3. Мадярова Д.Ә. – төзелеш һәм халык яшәешен тәэмин итү бүлеге баш белгече;
4. Гыйлаев Ф.М. – координация советы рәисе, АПК хезмәткәрләре профсоюз комитетының Тукай районы комитеты рәисе;
5. Хәбетдинова Г.Ф. – «Тукай муниципаль районы мәгариф идарәсе» МКУ башлыгының укыту эшләре буенча урынбасары;
6. Муленкова В.Р. – «Тукай муниципаль районы бюджет һәм казна учреждениеләренә хезмәт күрсәтү үзәге» МБУ җитәкчесе;
7. Хәкимова Э.В. – Татарстан Республикасы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге дәүләт казна учреждениесенең Яр Чаллы шәһәре һәм Тукай районы буенча департаментының Тукай районы буенча гражданнарны кабул итү бүлеге башлыгы;
8. Лымарь Р.Р. – Тукай районы үзәк хастаханәсе баш табибы.

Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2025 елның ___ 24.09. ___ 3188 номерлы карарына 2 кушымта

**2024 елга Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының ведомство буйсынуындагы оешмаларда хезмәт законнарының һәм хезмәт хокукы нормаларын үз эченә алган башка норматив хокукый актларның үтәлешенә тикшерүләр үткәрү планы**

**Тикшерүләр үткәрү максаты:** Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының ведомство буйсынуындагы оешмаларда хезмәт законнарының һәм хезмәт хокукы нормаларын үз эченә алган башка норматив хокукый актларның үтәлешенә ведомство контроле.

| № | Ведомство буйсынуындагы оешманың исеме | Ведомство буйсынуындагы оешманың урнашу урыны | Тикшерү үткәрүнең формасы (документар яки күчмә) | Планлы тикшерү үткәрү чоры | Тикшерү үткәрү срогы |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Калмаш төп гомуми белем бирү мәктәбе» МБГББУ | Тукай муниципаль районы, Калмаш авылы, З. Галиева ур., 13. | Документар | 2025 елның IV кварталы | 20 эш көне |
| 2 | «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Круглое Поле төп гомуми белем бирү мәктәбе» МБГББУ | Тукай муниципаль районы, Круглое Поле пос., Гагарина ур., 11А. | Документар | 2025 елның IV кварталы | 20 эш көне |